ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2018 ел № 26/9

Муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 маддәсенә, 2017 елның 22 декабрендә Россиянең социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрне җайга салуның өчъяклы комиссиясе карары белән расланган федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдә 2018 елда дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең Бердәм рекомендацияләренә (11 беркетмә), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 413 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше 52 пунктына нигезләнеп,
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:
1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль китапханәләрендә, музейларында, музей тибындагы башка учреждениеләрдә һәм мәдәни – ял муниципаль учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәне 1 нче кушымтада каралган тәртиптә;
2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль башкару сәнгате учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәне 2 нче кушымтада каралган тәртиптә;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләрендә фәнни тикшерү һәм фәнни эш хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәне 3 нче кушымтада каралган тәртиптә;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәне 4 нче кушымтада каралган тәртиптә;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләрендә гомуми тармак эшчеләре һәм гомуми тармак җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацон төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәне 5 нче кушымтада каралган тәртиптә.

2. Әлеге Карарның 1 пункты белән муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә билгеләнгән хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфалары күләме һәм квалификацияләре үзгәрешсез калган очракта, Карар нигезендә хезмәт хакы түләүгә кадәр гамәлдә булган хезмәт хакына түләү системасында түләүдән ким булмаска тиеш.

3. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының 2010 елның 26 августындагы 53/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең аерым муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 22/8 санлы Карарының 6 пунктын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 08 февральдәге 10 нчы санында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 23/6 санлы Карарының 2-5 пунктларын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 06 марттагы 17 нче санында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 25/7 санлы Карарының 3-5 пунктларын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 11 июньдәге 44 нче санында бастырылган;

4) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү өлкәсендә аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 26/5 санлы Карарын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2013 ел, 13 сентябрьдәге 69 нчы санында бастырылган;

5) Шәһәр Советының 2014 елның 10 августындагы «Шәһәр Советының хезмәткә түләүнең яңа системасы өлкәсендә аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 31/7 санлы Карарының 2-5, 7 пунктларын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2014 ел, 16 июльдәге 51 нчы санында бастырылган;

6) Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү өлкәсендә карарларына үзгәрешләр кертү турында» 35/7 санлы Карарының 5 пунктын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2014 ел, 17, 19 декабрьдәге 94-95 саннарында бастырылган;

7) Шәһәр Советының 2017 елның 29 мартындагы «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын җайга салу өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 16/6 санлы Карарының 1, 2 пунктларын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2017 ел, 07 марттагы 24 нчы санында бастырылган;

8) Шәһәр Советының 2017 елның 10 августындагы «Муниципаль учреждениеләрнең аерым категория хезмәткәрләрнен хезмәтенә түләүгә үзгәрешләр кертү турында» 18/5 санлы Карарының 1 пунктын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 11 августтагы 59 нче санында бастырылган;

9) Шәһәр Советының 2018 елның 21 февралендәге «Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренен хезмәтенә түләү турында Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 23/8 санлы Карарының 4-6 пунктларын, «Челнинские известия» газетасының 2018 ел, 14 марттагы 17 нче санында бастырылган.

4. Әлеге Карар 2018 елның 01 сентябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев